| | |
|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.09.2019 Казан шәһәре № 5-5/тэ

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2016 № 5-74/тэ карары кушымтасына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 5-108/тэ карарын көчен югалткан дип тану турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2019 елның 22 августындагы 280 номерлы, эшчәнлекнең җайга салынулы төрен гамәлгә ашыруны туктату турындагы мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Җылылык челтәрләре оешмалары тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә 2017-2019 елларга тарифлар билгеләү турында» 16.12.2016 № 5-74/тэ карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 5-90/тэ, 19.12.2018 № 5-103/тэ карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кушымталарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 2 нче, 3 нче пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

2 нче кушымтаның 2 нче пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019 елга «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган

җылылык энергиясен тапшыру хезмәтенә тарифлар билгеләү турында» 2018 елның 19 декабрендәге 5-108/тэ номерлы карарын көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев